| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2020 Баулы шәһәре № 131

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2017 елның 25 октябрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртипне саклау кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктының 60 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, бетерелә торган яки бетерелергә тиеш җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба - калдыклар) - җитештерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү процессында яки куллану

процессында барлыкка килгән матдәләр яки предметлар». Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кулланыла торган су төбендәге грунт калдыкларга керми.».

2. Әлеге карарны www: pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм www: Bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

4. Әлеге карар 2020 елның 14 июнендә үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе

Р.Х. Гатиятуллин